**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОМСОМОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«04» февраль 2021 ел № 04

«Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 19 ноябрендәге 55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясенең 2021 елның 4 январендәге ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 19 ноябрендәге 55 номерлы карары белән расланган Административ регламентның 2.6 пунктына үзгәрешләр кертеп, яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем алырга мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган) өземтә.

2) Авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе О.В. Сурова